**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

БОЕРЫК

11.03.2013 Казан ш. № 11-26

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында**

“Коррупциягә каршы тору турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 22 декабрь, 2015 ел, № 650 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибен (кушымта итеп бирелә) (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) (Мәкъсудова Г.Х) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты (алга таба – Казначылык департаменты) (Старцев И.А.) аппаратының кадрлар бүлекләре начальникларына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Министрлык һәм Казначылык департаменты аппаратындагы дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен, шулай ук, хезмәт контрактларын төзегәндә, гражданнарны бу боерык белән таныштыруны;

Тәртипне Министрлык, Казначылык департаменты һәм Казначылык департаментының территориаль бүлекләре биналарындагы “Стоп-коррупция” мәгълүмати стендларында урнаштыруны;

бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрүне.

3. Гомуми бүлекнең әйдәп баручы белгече – матбугат секретарена (Гапсәләмова Д.К.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталындагы Министрлык сайтына “Коррупциягә каршы тору” бүлегенә урнаштырырга.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы Финанс Министрлыгының 11.03.2016 ел, № 11-26 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибе**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында үзләренә карата эшкә яллаучы булып Татарстан Республикасы финанс министры (алга таба – министр) торган дәүләти гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре, Министрлык) тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү процедурасын җайга сала.

2. Гражданлык хезмәткәре вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында, бу хакта үзенә мәгълүм булган көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча, министрга хәбәр итәргә тиеш.

3. Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр гражданлык хезмәткәре тарафыннан, бу Тәртипкә № 1 кушымтада китерелгән формада, язмача уведомление рәвешендә тутырылып, министрга җибәрелә.

4. Министр өч эш көне эчендә уведомлениене, башлангыч төстә карап тикшерү өчен, Министрлыкта коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

5. Җаваплы зат, бу Тәртипкә № 2 кушымта нигезендәге форма буенча, кабул итеп алынган Уведомлениеләрне Теркәү журналында теркәүне һәм учетын алып баруны хәл итә. Уведомление җибәргән гражданлык хезмәткәренә, теркәү турында билге белән, уведомление күчермәсе тапшырыла.

6. җаваплы зат гражданлык хезмәткәреннән алынган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында мәгълүматларның яшеренлеген һәм сакланылышын тәэмини итә һәм, Россия Федерациясе законы нигезендә, әлеге мәгълүматларны таралуына персональ җавап бирә.

7. Уведомлениене башлангыч төстә карап тикшерү барышында җаваплы зат уведомлениене җибәргән гражданлык хезмәткәреннән уведомлениедә бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алуга, дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынулы оешмаларга билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрүне тәкъдим итүгә хокуклы.

8. Уведомлениенең башлангыч төстә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы зат нигезле бәяләмә әзерли. Башлангыч карап тикшерү барышында алынган уведомление, бәяләмә һәм башка материаллар, җаваплы зат тарафыннан уведомление кабул итеп алынганнан соң җиде эш көне эчендә, җаваплы зат тарафыннан Министрлык яки казначылык департаменты аппаратында дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча тиешле комиссия (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

9. Бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән запрослар җибәрелгән очракта, уведомление, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан тиешле Комиссия рәисенә уведомление алынганнан соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма күп дигәндә 30 көнгә генә.

10. Комиссия, кабул итеп алынганнан соң җиде эш көне эчендә, уведомлениене, бәяләмә һәм башка материалларны карап тикшерә һәм карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Финанс министры боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә туры китереп карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгында дәүләти гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган
яки китерә алу ихтималы булган
вазыйфаи бурычларны
үтәгәндә
шәхси кызыксынуның килеп
чыгуы турында хәбәр итү тәртибенә
№1
кушымта

Татарстан Республикасы Финанс
министрына

___________________________________
(Ф.И.О.)
...
_______________________________дән
(вазыйфасы, Ф.И.О.)

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китергән яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе турында
Уведомление

Түбәндәгеләрне хәбәр итәм:

1.

_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
(мәнфәгатьләр бәрелешенә китергән яки китерә алырдай хәлләрнең тасвирламасы)
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________

2.

_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
(үтәлешенә гражданлык хезмәткәренең шәхси кызыксынуы тискәре йогынты ясарга мөмкин булган яки тискәре йогынты ясаган вазыйфаи бурычларның тасвирламасы)
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________

3. ______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(гражданлык хезмәткәре күрсәтергә кирәк дип санаган өстәмә мәгълүматлар)

_____________ _______________ ________________________________

(дата) (имзасы) (инициаллары һәм фамилиясе)

Таныштым____________________________________

(гражданлык хезмәткәренең турыдан-туры начальнигы)

_____________ _______________ ______________________________

(дата) (имзасы) (инициаллары һәм фамилиясе)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алу ихтималы булган вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибенә №2 кушымта

Килеп туган яки килеп туу ихтималы булган низаг турында
уведомлениеләрне теркәү журналы

Башланды"__"________20_ел

Тәмамл. "__"_______20__ел
______ битле.

| Уведомление теркәү № һәм датасы | уведомление тапшырган гражданлык хезмәткәре турында мәгълүматлар | | | Уведомление не кабул итеп алган затның фамилиясе һәм инициаллары | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | фамилия, имя, отчество (при наличии) | должность | номер телефона | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |